СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*9 декабрь, 1998 ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 140 (8297)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ТОРМЫШНЫ ҮЗ АГЫМЫНА КУЕП БУЛМЫЙ

**(Район активы киңәшмәсеннән)**

Әле узган дүшәмбедә генә район хакимиятендә булып узган зур семинар - киңәшмәдә беренче чиратта терлекчелек мәсьәләләренә багышлап зур сөйләшү булганлыгы турында тәфсилләп язган идек. Һәм менә нәкъ бер атнадан соң,бу юлы инде тагын да зуррак контингент белән шул ук темага тагын да җитдиерәк һәм киңрәк сөйләшү үтте. Хакимият башлыгы Ф.С. Сибагатуллин моңа сәбәпнең бик җитди булуын сүзенең башында ук үтемле иттереп әйтеп узды. Республикада халыкны азык - төлек белән тәэмин итү мәсьәләсенең соңгы вакытта шактый ук кискенләшүе, һәм моңа беренче чиратта авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм хәзерләүнең артуга бармавы сәбәп булса, икенчедән, аларны читкә озатуларны чикләү зарурияты бар җитдилегендә алга килеп басты. Хөкүмәт авыл товар җитештерүчесенә карата чын -чынлап йөз белән борылу сәясәте алып барган шартларда бездән бары бер генә нәрсә сорала - терлекчелектә тотрыклылыкны саклауга ирешергә, продукция җитештерүне арттыруның бар мөмкинлекләрен эшкә җигәргә, җитештерелгән продукцияне үзебезгә дә, дәүләткә дә отышлы булырлык иттереп урнаштыру чарасын күрергә кирәк.

Җитештерүгә килгәндә, хакимият башлыгы иң элек узган атна ахырында Президент М.Ш.Шәймиевның хакимият башлыклары һәм башка җаваплы хезмәткәрләр белән Биектау районы базасында уздырылган семинар - киңәшмәсе йомгаклары белән тәфсилләп таныштырды. Биектауда безнең күпчелек хуҗалык җитәкчеләренә яхшы таныш алдынгы хуҗалыкларда терлекчелектә эшне элеккечә үк эзлеклелек белән тотрыклы алып баралар икән һәм чын хуҗаларча эш итеп, менә дигән нәтиҗәләргә ирешәләр. Ул җәһәттән безнең районда да терлекчелектә чыгымнарга каршы механизмга корылган стильдә эш итеп әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирешүче хуҗалыклар аз түгел. Әмма терлекчелекнең асылын тәшкил итүче технология таләпләрен тайпылышсыз үтәү эше барлык хуҗалыкларда да тиешле дәрәҗәдә түгел әле. Аерым алганда, хакимият башлыгы бу тармакта нәсел эшенә һәм селекция мәсьәләләренә бик җитди карау зарурлыгын кабат - кабат ассызыклады. Шунсыз мөмкин дә түгел, чөнки малларны бәйләүсез асрау алымын кертү баръяклы уйлап гамәлгә ашырылмый икән, терлекләрнең иясез калуына юл кую бик тиз, ә моның исә нәкъ менә нәсел - селекция эшенең күздән дә, кулдан да ычкынуына китерәчәге бәхәссез. Кызганычка каршы, семинар - киңәшмәләрдә күп тапкырлар тәкърарлап һәм ачык аңлатылып килсә дә, нәсел - селекция эше мәсьәләләре күп кенә хуҗалыкларда үзагымга куелган әле. Ә бу терлекчелекнең иртәгәге көне ничек буласы турында уйламау дигән сүз. Районга махсус килгән вәкил - “Татмясопром” холдинг компаниясе президенты Ә.Г. Булатов та киңәшмәдә ясаган чыгышында нәкъ менә шуңа игътибар юнәлтте. Нигездә үзләренә караган “Нурлат” агрофирмасы хуҗалыклары мисалында гына булса да Әхмәтҗан Галимҗанович терлекчелекне алып баруда күп кенә мөһим мәсьәләләрнең күз уңыннан ычкынуы һәм моның аяныч нәтиҗәләргә китерүе турында бик борчылып сөйләде. Аның теге яки бу тармакта эшнең торышына бик нигезле һәм гыйбрәтле мисаллар белән анализ ясавы җитәкчеләрне җитди уйландырыр дип ышанасы килә. Ф.С.Сибагатуллин да бу сөйләшү моның белән генә тәмамланырга тиеш түгел, алга таба ничек яшәү, хәлне ничек тотрыклыландыру, уртак көч белән җайга салу турында урыннарда белгечләр катнашында җитди киңәшмәләр, хәтта хуҗалыкларның гомуми җыелышларын яки авыл җыеннарын уздыру максатка ярашлы дип басым ясап үтте. Анысы терлекчелек продукциясе җитештерү һәм хәзерләүне арттыруда барлык мөмкинлекләрне дә, җәмәгать терлекчелегенең генә түгел, шәхси хуҗалыкларның да резервларын тулысынча эшкә җигү зарурлыгыннан килеп чыга. Хакимият башлыгы шәхси хуҗалыкларның мөмкинлекләрен тулырак эшкә җигү зарурлыгы турында болай да адым саен кабатлап килә. Менә бу киңәшмәгә дә хуҗалык рәисләре, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләре белән бергә җирле үзидарә башлыклары да чакырылган иде. Соңгыларының алдында торган бурычлар шулай ук җитди - шәхси сектордан ит - сөт, башка төр продукциянең халыкның үзеннән артканын сатып алу эше бер генә көнгә дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Бу шушы җирдә, шушы урында үскән азыкны ашатып җитештерелгән продукциянең читкә китмәве ягыннан да мөһим, бу акчасызлык заманында халыкны даими рәвештә тере акча белән тәэмин итеп тору җәһәтеннән дә кыйммәт. Ул максатларның беренчесе уңаеннан киңәшмәдә шәһәр һәм район эчке эшләр бүлеге башлыгы В.В. Иванов чыгыш ясаса, хәзерләү эшчәнлеген ничек кабаттан аякка бастыру турында район кулланучылар җәмгыяте рәисе М.С.Моратов тыңланды.Эчке эшләр бүлеге башлыгы продукцияне район һәм республика чикләреннән чыгаруларны чикләү буенча милициянең шактый эш башкаруын әйтү белән бергә, урыннарда матди байлыкка сак карау юнәлешендә хуҗалыкларның үзләрендә дә тиешле эш оештырылырга тиешлеге, моңа игътибар итмәүнең нинди аяныч нәтиҗәләргә китерүе турында җитди сүз кузгатты, ә менә хәзерләүләр эшчәнлеген ничек җайга салуның ачык перспективасы күзалланмый икән әле.

**(Ахыры 3нче биттә).**

# 12 ДЕКАБРЬ - ШӘҺӘР КӨНЕ

## *Хөрмәтле нурлатлылар!*




***12 декабрь көнне ипподром мәйданында “Шәһәр көне”нә багышланган зур бәйрәм була.***

***<u>Бәйрәмнең программасы түбәндәгечә:</u>***

***1. Бәйрәмне тантаналы ачу.***

***2. Спорт ярышлары һәм спорт - күңел ачу уеннары.***

***3. Нурлат шәһәре призына Мәскәү, Казан, Түбән Кама, Яр Чаллы, Тольятти, Ижевск, Ульяновск, Самара шәһәрләреннән Россиянең иң көчле спортчылары катнашында кышкы трек автомобиль узышлары.Аннан соң стартка "Буран"нар басачак (ярышка чыгарга теләүчеләр хәзердән теркәлергә тиешләр).***



***4. Сәүдә предприятиеләре - Нурлат район кулланучылар җәмгыяте, “Нурлатнефть” НГДУсы, тимер юл һәм урман хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, район хуҗалыклары һәм предприятиеләре кибетләре, шәхси эшмәкәрләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре сатучылары катнашында зур ярминкә.***

***Бәйрәмдә пар атларда мәйдан әйләнү мөмкинлеге булачак. Иң җитез һәм матур бизәлгән атларга урыннар билгеләнәчәк. Ярминкәдә иң мул товар белән катнашкан һәм сәүдә нокталарын матур итеп бизәп, халыкка культуралы хезмәт күрсәткән сәүдә оешмалары һәм хуҗалыкларга да махсус урыннар каралган.***



***Бәйрәм 9.00 сәгатьтә башлана.***

***11 декабрь көнне автоузышларда катнашучылар өчен контроль үтү билгеләнә.***

***Хөрмәтле нурлатлылар, кунаклар! Шәһәр көненә рәхим итегез!***

# СҮЗ - БӘЙРӘМГӘ ӘЗЕРЛЕК ТУРЫНДА

Узган шимбә көнне шәһәр оешма - предприятиеләре, учреждениеләре җитәкчеләре катнашында “Шәһәр көне”н үткәрү буенча эшче киңәшмә булды. Аны район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев алып барды. Шәһәр бәйрәменә әзерлекнең барышы турындагы информацияне район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Х.Абдуллин ясады. Киңәшмәдә бу кышкы бәйрәмне һәрьяклы әзерлек белән каршы алу, массакүләм төстә кызыклы итеп үткәрү өчен тиеш булганнарның барысын да кичектергесез башкарырга кирәклеге турында тагын бер кат ассызыкланды, агымдагы мәсьәләләр каралды, бәйрәм чараларына кертеләсе өстәмәләр бәян ителде.

# ҖАН АЗЫГЫ АЛДЫК

**ФИКЕР**

Узган шимбә көнне район мәдәният йортында Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт Әсәдуллинның гаҗәеп матур концерты булды. Концерт ике телдә алып барылды, җырлар хәтта өч телдә башкарылды. Танылган милләттәшебезнең таланты кичәне бик матур бәйрәмгә әверелдерде: ул зал белән ике арада эчкерсез бәйләнеш урнаштыра алды, тыңлаучыларның сорауларына бик теләп, иренмичә җаваплар бирде. Татарстанда туып, Санкт - Петербургта җырчы булаграк формалашкан Әсәдуллинның үз милләте, туган җире, әнисе белән горурлануы бездә чиксез соклану уятты. Аның дәрәҗәсендәге артистның Нурлат сәхнәсендә чыгыш ясавы - безнең өчен озак истә калырлык вакыйга иде, билгеле. Өстәвенә, артист үз чыгышын бушлай үткәреп, сәнгатькә гашыйк һәр җан өчен аны карау мөмкинлеге бирде. Альберт әфәнденең әйтүенчә, бу адымны ясауда район хакимияте башлыгы белән шәхси дуслык хисе нигез булган. Шуңа җырчыга рәхмәт юллаганда, нурлатлыларның рухи тормышын баету турында кайгырткан хакимият адресына да җылы сүзләребезне җиткерәсебез килә. Хезмәт кешесенә җан азыгы да зур канәгатьлек бирә бит!

**Р.ГИНЯЕВА.**
**4нче мәктәп директоры.**

*<u>Инвалидлар декадасы бара</u>*

# МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК ЭЗСЕЗ КАЛМАС

Сукырлар җәмгыятенең районара оешмасы инвалидлар көнен зурдан билгеләп үтте. 3нче декабрьдә берниндиоешма, предприятие карамагында да булмаган 22 начар күрүче һәм бөтенләй күрмәүче кешеләр чәй табыны артына җыелдылар. Аларның күңелләрен күрү өчен район мәдәният йортыннан тулы концерт бригадасы чакырылды. Л.Җиһаншина рус, С.Котдусова татар, М.Илларионова чуваш җырларын башкардылар, ә С.Миннеханов баяны белән аларның җырларына да кушылды, үзе дә җырлады. С.Камитов эстрада монологлары белән кәефләрне күтәрде. Концертны В.Голубева алып барды.

Соңыннан язмыш тарафыннан кимсетелгән кешеләргә бүгенге авыр вакытта ярдәм йөзеннән әзерләнгән ашамлыклар пакеты таратылды. Бу күчтәнәчләрне һәм чәй табынын әзерләргә булышлык күрсәткән азык - төлек комбинаты, икмәк һәм сөт - май заводлары, ит комбинаты, элеватор җитәкчеләренә зур рәхмәтебезне ирештерәсебез килә. Инвалидлар өчен бу көн чын бәйрәмгә әйләнде, шул кечкенә генә мәрхәмәтлелекне дә алар югары бәяләп, зур канәгатьлек белән өйләренә таралыштылар.

**З.БОГДАНОВА,**
**Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең районара оешмасы рәисе.**

# «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

# Төрнәс спирт заводы: ЯҢАДАН ТУУ



**Бу мөһим объект турында без моңарчы газетада бер генә җөмлә яза килдек: "Югары сыйфатлы "Люкс" спирты, сыйфатлы аракы чыгарачак, шуның белән район бюджетына байтак керем бирәчәк". Әмма бу максатка ирешкәнче, Төрнәс спирт заводында гаҗәеп зур хезмәт нәтиҗәсендә тамырдан реконструкция баруын яктыртканыбыз булмады. Хәзер дә әлеге катлаулы производство, зур хуҗалыкта барган күпкырлы хезмәт турында тулысынча сөйләп җиткерү максатын куймыйбыз, ул бер генә язмада мөмкин дә түгел. Әмма газета укучыларыбызда районның удар төзелеше рәвешен алган бу объект турында гомуми күзаллау булырга тиеш, дип саныйбыз.**

Төп сүзгә керешкәнче, бераз гына чигенеш ясыйк: "Төрнәс спирт заводы" дәүләт унитар предприятиесе - "Татспиртпром" берләшмәсендә бары чимал гына җитештерүче бердәнбер предприятие булып калган иде инде. Чималга сорау да тыйнак, бәя дә - чикле. Шуңа предприятиене үзгәртеп кору зарурлыгын заман үзе байтактан сиздерә килде. Әмма бу бинаһая зур эшне кузгатып җибәрүче итеп район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинны атыйлар. Хаким "Татспиртпром" берләшмәсе җитәкчелеге белән уртак тел табып, моннан бер еллар элек бозны кузгатып җибәрүгә иреште. Ә төзелешкә икенче сулыш өргән вакыйга итеп бирегә ТР Премьер - министры Р.Н.Миннеханов килүен атыйлар. Премьер үзе күреп, объектның зур киләчәгенә инангач, матди ныгыту бүленгәч, аны өлгертүнең конкрет сроклары билгеләнгәч, төзелеш чын мәгънәсендә удар төс ала. Чөнки сроклар бик кыска була: быел чиста спирт җитештерү эшен башлап җибәрергә. Ә бу - бер заводны гына түгел, спирт җитештерү белән турыдан - туры бәйле күп башка - су белән тәэмин итү, канализация, электрлаштыру, чимал саклау склады, лаборатория, котельня хуҗалыгы һ.б. мәсьәләләрне хәл итүне тизләтүне дә сорый иде. Хәзер Төрнәстә шул бер максатка буйсынган күп юнәлешле хезмәтнең иң кызган чагы.

- Бүген дә бездә 20ләп эре подрядчы эшли, гомуми исәпләгәндә, алар саны 30лап җыелгандыр,- дип каршылады безне "Төрнәс" спирт заводы дәүләт унитар предприятиесе директоры Р.Г.Сунеев. Әйе, завод территориясе дә, аның конторасы да умарта оясын хәтерләтә иде. Подрядчыларның һәрберсе үз эшен иң мөһиме итеп саный, күрсәтелгән срокка сыешыр өчен эшләр ике сменада алып барыла. Заводны реконструкцияләүдә коллективның 120 кешесе дә турыдан - туры катнаша, барлык инженер - техник хезмәткәрләрнең дә мәшәкате чиктән ашкан. Төзелешкә "Татспиртпром"нан 4 - 5 белгеч контрольлек итә, аларның берсе - баш белгеч Павел Иванович Дьяконский инде айга якын биредә яшәп булыша һәм беренче продукция алганчы беркая кузгалырга уйламый. Үз тармагында "поты белән тоз ашаган" Павел Иванович - төп технолог та, иң таләпчән инженер да, прораб та, электрик та... - югары сыйфатлы продукция җитештерү өчен һәр участокның төгәл эшләве кирәк булачак.

Ә шулай да, заводта нинди үзгәрешләр көтелә соң? Иң әүвәл шуны әйтергә кирәк: чимал җитештерүдән сыйфатлы продукция җитештерүгә күчү - заводны яңабаштан үзгәртүне таләп итә. Бу - тулаем яңа схема, яңа җиһазлар белән эшләячәк өр - яңа заманча предприятие булачак. Андый завод республикада юк, дөньяда да - бармак белән генә санарлык. 1100 декалитр чимал спирты җитештерүче завод реконструкция нәтиҗәсендә проект куәте 2000 декалитр иң чиста "люкс" һәм "экстра" спирты җитештерүче предприятиегә әйләнәчәк. Бу тулаем үзгәртеп кору дигән сүз. Әйтик, пешерү станциясе (станция разваривания) әлегәчә 30нчы еллар дәрәҗәсендә генә булган. Реконструкция вакытында түбән температуралы механик - ферментатив схема кертеләчәк. Бу схема 40 - 45 градуска кадәр җылылык энергиясенә экономия ясарга мөмкинлек бирәчәк. Шуның нәтиҗәсендә 1 тонна чималдан продукция алу күләме артачак, аның сыйфаты яхшырачак. Бу хакта П.И.Дьяконский тулы белешмә бирә: элек чимал җитештерү өчен температураны 146 градуска кадәр җиткергәннәр. Югары температура вакытында чимал яна, катнашмалар күп барлыкка килә. Киләчәктә спирт җитештерү өчен 90 градустан артмаган җылылык кулланылачак.

Икенче үзәк цех - ачыту цехы да киңәйтелә, үзгәртеләчәк. Биредә ачыту срогын 72 сәгатьтән 64 - 56 сәгатькә кадәр кыскарту күздә тотыла. Ә бу заводның җитештерүчәнлеге арту - суга, энергиягә экономия дигән сүз.

Яки өченчесе - элек бер ачыткы кудыру (брагоперегонный) колонна булса, хәзер 5 колонналы җайланма куелачак, шуның нәтиҗәсендә энергияне экономияләргә мөмкин булачак, әйтик, җылылык энергиясе 20 процентка азрак соралачак. Биредә катнашмаларны концентрацияләү һәм ахыр чистарту колоннасы куллану спиртның сыйфатын гарантияли, спиртның тулаем чыгышы да 2 - 2,5 процентка артыграк булачак. Иң мөһиме, элек бердәнбер автоматикасы - монометры гына булган завод тулысынча автоматлаштырылачак, җитештерү белән компьютер ярдәмендә идарә итү күздә тотыла. Билгеле, шундый заманча яңартуга барлык биналар, шул исәптән лаборатория дә дучар ителә. Яңа лабораториядә экспресс анализ ясау өчен заманча приборлар куелачак, ул чимал лабораториясе, спирт һәм җитештерү лабораторияләрен берләштерәчәк. Гомумән, әйткәнебезчә, спиртзавод хуҗалыгы яңабаштан корыла. Биредә башкарыласы эшләрне тулысынча белим дисәң, "Завод биналары һәм корылмаларының титул исемлеге"н карарга кирәк. Анда спирт җитештерү, канализация, барда тарату комплексы, спирт саклагыч, бөртек саклау склады, гаражга реконструкция һ.б. каралган. Электр энергиясенең 2нче фидеры сузылган, чистарту корылмаларын булдыру гына да 5 миллионга төшәчәк. Газ белән эшләүгә күчерелгән котельня Төрнәснең социаль объектларына да җылы бирерлек итеп ясала. Бу һәм тагын әллә никадәр эшләрне төгәлләү срогы итеп 2000нче ел күрсәтелә. Шулай итеп, реконструкция заводның үзенә генә түгел, тулаем совхоз тормышына да зур үзгәреш бирәчәк, ә инде хәрәкәткә киткәч, аның нәтиҗәләре район, республика тормышына да яңа сулыш өрәчәк.

Бу көн кайчан булыр дисезме?



Биредә пешерү станциясе булачак.



Спирт саклагычны киңәйтү;

Завод җитәкчелеге әйтүенчә, декабрьнең 25нә кадәр алар төзү - монтаж эшләрен төгәлләп, җибәрү - көйләү эшләренә күчәргә һәм яңа ел алдыннан беренче продукцияне алып карарга ниятлиләр. Бу планны гамәлгә ашыру җиңел булмавын беләләр, әмма, Премьер - министр Р.Н.Минеханов әйткәнчә, хәзер артка юл юк, бары алга гына барырга. (Сүз уңаеннан, Премьерның бу объект белән кызыксынуы кимеми, 7 ноябрь көнне киңәшмәдә ул объекттагы эшләрнең барышын җентекләп сорашкан). Шуңа завод җитәкчелеге бүген эшнең иң үзәгендә кайнаган подрядчылар - "Тимер" проект җитештерү фирмасы (В.П.Андрианов), КМУС (Г.Д.Җиһаншин), "ДАН" фирмасы (И.Ю. Галиев), Чаллы двигатель - монтаж идарәсе (Р.Г.Фанян), РИК - 2 (А.А.Галиуллин), үзебезнең 127нче ПМК, 547нче ПМК коллективларына һ.б.га бик рәхмәтлеләр. Ә инде завод өчен кадрларны яңабаштан әзерләү чарасын алдан ук күрделәр: белгечләр төрдәш предприятиеләрдә практик өйрәнүләр үттеләр, квалификация күтәрү курсларында укыдылар, "Татспиртпром" каршындагы профтехучилищеда белемнәрен күтәрделәр. Әлбәттә, күп нәрсәне эш барышында да үзләштерергә туры киләчәк әле, аны сын да аңлыйлар. Чөнки бит шулкадәр акча сарыф итеп төзелгән заводтан сорау да зур булачак: сыйфатлы продукция республиканың гына түгел, РФ регионнарының да базарын яуларга, анда ныклы репутациясен сакларга һәм ахыр максат - даими рәвештә тере акча эшләргә тиеш булачак. Базарга, билгеле, спирт түгел, чиста аракы чыгару күздә тотыла. Шуңа да заводның тагын бер мөһим ноктасы - аракы эшләү линиясе булачак һәм аны эшкә җибәрүне озакка сузмау хакында да сүз беренче көннәрдән үк алып барыла. Ул гамәлдә дә шулай булыр, мөгаен: төрнәслеләр ТР Министрлар Кабинетында бу җәһәттән Германиянең "Кронас" фирмасыннан аракы - ликер заводына 3 комплект җиһазлар сатып алу турында карар кабул ителүен, ул заводның берсе - безгә булачагын әйттеләр. Бу өлкәдә данлыклы фирма җиһазлары шулай ук иң заманча, иң кызыгырлык икән.

Төрнәс спирт заводы бүген менә шундый мәшәкатьләр белән яши. Рәхмәт авыл кешеләренә - подрядчыларның күбесен алар яшәп торырга керткәннәр, ашханәдә 3 тапкыр ризык әзерләнә - пешекче кызларга шулай ук эш җитәрлек. Конторада төяү - бушату, түләү - күчерү, кайтару, табу кебек мәшәкатьләр белән подрядчылар, белгечләр телефон чылтырата, факс юллый, директорны йөдәтә. Киеренкелек, хәрәкәт зур, эш тыгыз. Әмма, безгә калса, һәрберсе үзенең мөһим һәм бәһале эштә катнашуын аңлый һәм заводның беренче продукция җитештерәсе көнен якынайту өчен үзеннән көтелгәнне артыгы белән башкарырга әзер иде. Ә фидакарьләр булган җирдә сүз эштән аерылмый ул.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА**
**Н.АЗИЗОВ фотолары**

# Сез хыянәт итмисез. Шулай бит?!

**“Ө**йләнү ирләр тормышында зур бер вакыйга, хатын - кызлар өчен кияүгә чыгу - тормышның үзе”,- ди шагыйрь. Ир - атларның еш кына гаиләсенә һәм хатынына хыянәт итүе мәгълүм нәрсә. Ләкин барлык ирләргә дә “хыянәтче” дип мөһер сугарга ярамый. Шулай ук, “барлык хатыннар да ирләренә тугрылыклы” дисәк хата булыр иде.



Ир белән хатынның бер - берсенә хыянәт итү очраклары шактый дәрәҗәдә тормыш шартларына бәйле. Шулай да, ни өчен ирләр хатыннарга караганда ешрак хыянәт итә соң? Психолог Айхан Кальйонжу фикеренчә, җәмгыять ирләрне һәм хатын - кызларны балачактан ук төрлечә тәрбияли. Сер түгел бит: бездә дә, сездә дә “ир кеше хатын - кызга караганда бар яктан да өстенрәк”, дигән караш хакимлек итә. Шунлыктан ирләр яшьтән үк: “безгә ни эшләсәк тә килешә”, дигән фикерне сеңдереп үсәләр. Ирләрнең хатыннары өстеннән йөрүенә төп сәбәп тә әнә шунда.

Бер хатын (бер ир) белән гомер итү - зур бәхет ул. Гаилә корырга җыенган яшьләр моны яхшы аңларга тиеш. Өйләнешкәннән соң ир дә, хатын да чит кешеләр белән аралашканда чаманы онытмаска тиеш. Әлбәттә, һәр нәрсәне хыянәт галәмәте, дип санарга ярамый. Мәсәлән, матур, чибәр, мөлаем ир кеше яки хатын - кыз өйләнгән (кияүгә чыккан) кешеләрнең дикъкатен җәлеп итсә, моның бер гаебе дә юк. Ләкин монда чикне узарга ярамый. Әгәр өйләнгән кеше күңеленә хуш килгән башка җенестәгеләргә берәүгә мәгънәле итеп караса, бу хыянәт галәмәте булып санала.

### *КЕМНӘР КҮБРӘК ХЫЯНӘТ ИТӘ ҺӘМ МОНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ*

* Бер генә кеше белән озак вакыт никахта яши алмаучы бозык шәхесләр була. Алардан хыянәтне көт тә тор инде.

* Гаилә мохитеннән туйган, тормыш ямен җуйган кешеләр. Андыйлар хатынының (иренең) һаман өйдә булуын тели, беркем белән дә аралаштырмый. Хәләл җефетенең киемен дә, үз - үзен тотышын да тәнкыйтьли. Мондый кешеләр дә хыянәткә сәләтле.

* Хәләл җефетләренә феодалларча караучылар. Алар бик көнче була. Мондый кеше иренең (хатынының) хыянәт итүе өчен потенциаль мөмкинлек әзерли.

* Хыянәтнең иң зур факторларыннан берсе - җенси салкынлык, битарафлык. Хәзерге вакытта бала тапкан хатыннарның 35 - 40 процентында җенси теләк булмау күзәтелә һәм бу хәл 5 - 8 елга сузылырга мөмкин.

* Хәмер һәм наркотиклар белән дус кешеләр янынннан да хыянәт ерак йөрми. Андыйлар теләсә кем белән якын мөнәсәбәткә керә ала.

* Кайберәүләрдә даими рәвештә партнер алыштыру теләге була. Бу - патологик бозыклык. Әгәр кеше сөяркәләрен даими алыштыра икән, бу аның авыру булуы турында сөйли.

(“Заман - Татарстан”нан).

## СӨЙГӘН ЯРНЫ НИЧЕК САЙЛАРГА?

**СЫНАМЫШЛАР**

* Башын арткарак чөеп, югары тоткан хатын - кызда "Мин - мин икән, мин кем икән?" дигән авыру көчле була. Андыйларны буйсындырырмын димә.

* Очы өскә күтәрелеп торган "печтик" борынлы туташ вә ханымнардан ераграк йөрү хәерле. Бу - үтә явызлык билгесе.

* Зур авызлыларда сүз тормый. Серегезне чишә күрмәгез.

* Җәенке табак битле хатын - кыз ирен иркәләр, аның җаена гына торыр.

* Серле зат эзләсәгез, бит урталарында чокырчыклар булганнарга игътибар итегез. Алар ифрат мавыктыргычлар. Өстәвенә гаилә җанлылар.

* Соры күзлеләр ышанычлы. Тик кеше сөйләргә яраталар, гайбәтчәннәр. Ялкаурак та булмасалар, бәһасез булырлар иде.

* Ә иң яхшы кыз - күңелеңә хуш килгәне, әлбәттә.


НУРЛАТ СӘХНӘСЕНДӘ - РАМИЛ МИФТАХОВ



***БЕЛМИ КАЛМАГЫЗ, КИЛМИ КАЛМАГЫЗ!***

10 декабрьдә

***Район мәдәният йортында якташыбыз - композитор һәм башкаручы Рамил Мифтахов үзенең концерт бригадасы белән “Җырламыйча ничек түзим” дигән зур концерт программасы тәкъдим итә.***

Концерт 19.00 сәгатьтә була.

Билет бәясе - 10 сум.

***Инвалидлар үнкөнлегендә үтүен исәпкә алып, Рамил концерттан җыелган акчаның бер өлешен районның инвалидларга ярдәм фондына күчерергә нияте.***



***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 11нче һәм 25нче декабрьдә көндезге сәгать 12дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


### *Шифасы булсын!*



## БАЛАН

Татарстанда балан бик күп үсә. Аның җимешләрен тәмам өлгереп җиткәч, һава коры вакытта, сабагы белән кисеп алып җыялар. Ул әчкелтемрәк, ләкин өшегән баланның әчелеге кими. Балан витаминнарга, шикәргә, органик кислоталарга һ.б. матдәләргә бай. Баланның йөрәк эшчәнлеген яхшыртуы ачыкланган. Халык медицинасында аны эч йомшарту, тирләү, нервларны тынычландыру, бәвелне кудыру чарасы буларак та файдаланалар.

Балан согын болай ясыйлар: аны яхшылап юганнан соң кәстрүлгә салырга, 2 кг баланга 250 мл исәбеннән су өстәргә, утка куеп кайнатып чыгарырга, әмма озак итеп кайнатмаска кирәк. Уттан алганнан соң кайнатманы марля аркылы сөзәләр. Озак вакытка саклау өчен сокны яңадан җылытып, банкаларга яисә шешәләргә салырга һәм һава кермәслек итеп ябарга кирәк. 1 л сок ясау өчен 2 кг балан һәм 250 мл су кирәк. Йөкле хатыннарга баланнан ясалган әчемлекләрне куллану киңәш ителми.

## ЗӘЙТҮН МАЕ - ТЫЛСЫМЛЫ МАЙ

Соңгы елларда зәйтүннең әлегәчә ачылмаган шифалары мәгълүм булды. Төркиянең “Зәйтүн һәм зәйтүн мае берлеге” рәисе Җаһит Чәтин бу тылсымлы май турында менә нәрсәләр сөйли:

“Зәйтүн мае кан тамырларында кан оешуга юл куймый, шул рәвешчә, кан басымын көйли. Ул кандагы холестерин микъдарын киметә, ашказанының сеңдерү системасы эшчәнлеген җайга сала, гастритка һәм ашказаны җәрәхәтенә каршы бик нәтиҗәле чара буларак кулланыла.

Зәйтүн мае, ми тукымасының таушалуына юл куймау сәбәпле, картаю процессын да акрынайта. Аның составында булган Е витамины рак авыруыннан саклый. Зәйтүн маендагы А,Д,Е һәм К витаминнары, кальций, фосфор һ.б. минераллар сөяк үсешенә ярдәм итә. Моннан тыш, бу май тән тиресен картаюдан саклый, җыерчыклар барлыкка килү процессын шактый дәрәҗәдә тоткарлый.

(“Заман - Татарстан”нан).


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

### САТАБЫЗ

**Кулланышта булган йокы гарнитуры.** Тел.: 2-12-51.

***

**Хосусыйлаштырылган ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2-21-98.

***

**Йорт яны корылмалары белән өй (Нурлатта).** Каравыл Тавы авылында Шуяновка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Кулланышта булган бер ярымлы ике караваг кыйммәт түгел.** Тел.: 5-35-05.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**35 сумнан арзан булмаган яңа ел бүләкләре.** Тел.: 5-39-39.

***

**Гаиләгә (мәскәүлеләр) яшәп тору өчен (озак вакытка) өч бүлмәле фатир кирәк. АТП ягында, шәһәр үзәгендә булса әйбәтрәк.** Тел.: 2-19-84.

***

**Валерий Николаевич Широков исеменә документлар белән кара - көрән тәстәге визитка табучының бик зур бүләк бәрабәренә Абрыскино авылында Михаил Михайлович Мандрейкинга кайтарып бирүен сорыйм.**

***

**11 ноябрьдә, кич белән Карл Маркс урамының 4нче йорты янында соры таплы ак мәче югалды. Табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйм.** Адрес: К.Маркс ур., 4 - 33.

***

**Нурлат куллануччылар җәмгыятенең азык комбинаты халыктан килограммын 16 сумнан - дуңгыз ите, 15 сумнан сыер ите җыя. Түләү азык комбинаты кассасы аркылы башкарыла.** Белешмәләр өчен директорга 2-16-04, 2-21-15 телефоннары буенча мөрәҗәгать итәргә.

**Шипланган авторезина сатыла. Авторезинаны шиплау. Җиңел автомашинага резина сатып алам.** Тел.: 2-35-59, 5-35-91, кичке 5тән соң. Б - 97 № 28882 лицензия.

**Он, шикәр сатып алам.** Тел.: 2-11-13.

**Чикләнгән җаваплылыктагы Нурлат “ТН - РЭТО” җәмгыяте оешмалар һәм шәхси затларга түбәндәге электр җиһазларын ясый һәм ремонт үткәрә: ОПИ электродвигателе, 0,1 дән 160 кВтка кадәр, шул исәптән көнкүреш машиналары, батырма насослар.**

**ГД, АД серияле эретеп ябыштыру генераторлары, автогенераторлар, ПУ - 380 х 24 ВТ, 220 х 12 ВТлы кабызу җайланмалары, гаражлар өчен электр щитлары. Акчаны күчерү юлы белән дә, кулдан да түләргә була.** Тел.: 5-13-90.


### *Рәхмәт белдерәбез*

Җиләк - җимеш питомнигы директоры Владимир Петрович Сафандеевка матди ярдәме өчен олы рәхмәтемне белдерәм. Л.Кадыйрова.

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы хакимияте, халык депутатларының берләштерелгән Советы президиумы **әтисе Нил Мортаза улының** үлүе сәбәпле, район хакимияте башлыгының икътисад буенча урынбасары Фәрит Нил улы Гобәйдуллинның тирән кайгысын уртаклаша.

Район финанс бүлеге коллективы **әтисе Нил Мортаза улы Гобәйдуллинның** вафат булуы сәбәпле, район хакимияте башлыгының икътисад буенча урынбасары, район финанс бүлеге мөдире Фәрит Нил улы Гобәйдуллинның авыр хәсрәтен уртаклаша.

Нурлат район кулланучылар җәмгыятенең азык комбинаты **әтисе, комбинатның пенсионеры Нил Мортаза улы Гобәйдуллинның** вафат булуы сәбәпле, район хакимияте башлыгының икътисад буенча урынбасары, район финанс бүлеге мөдире Фәрит Нил улы Гобәйдуллинның авыр кайгысын уртаклаша.

“Дуслык” (“Дружба”, “Туслах”) район газеталары редакциясе **әтиләре, тормыш иптәше һәм агалары Нил Мортаза улы Гобәйдуллинның** вафат булуы сәбәпле, шәһәр һәм район хакимияте башлыгының икътисад буенча урынбасары Фәрит Нил улы Гобәйдуллинның, гаиләсенең, туганнарының, якыннарының авыр хәсрәтен уртаклаша.

“Дуслык” (“Дружба, “Туслах”) газеталары редакциясе 63нче яшендә озакка сузылган каты авырудан соң 60нчы - 80нче елларда газетаның мөхәррире, әдәби хезмәткәре булып эшләгән, соңгы елларын Казанда яшәгән **Наил Инсаф улы Хәйретдиновның** вафат булуын тирән кайгы белән белдерә һәм мәрхүмнең туганнарының, якыннарының, гаиләсенең авыр хәсрәтен уртаклаша.


МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә.